Индекс газеты - 52381

**Батырлар үстерәбез**

# Татар көрәшенең чишмә башы



Киләчәк Сабан туе батырлары

Февральнең 16нда Самарның “Яктылык” мәктәбе гөжләп торды. Йөзләгән эбер-чебер малайлар спорт мәйданында мәш килделәр. Барчасы да дулкын эчендә кайныйлар. Тиздән ярыш башлана. Ярыш башлануга зур бер малай көтүе икегә ярылачак. Беренчесе - җиңүчеләр, икенчесе - җиңелүчеләр.

Урындыкларда утыручы ата-аналар да ким борчылмыйлар. Шулай да тамашачылар арасында ир-атларның күбрәк булуы күзгә ташланды. Әтиләр дә егет чакларын исләренә төшереп, кемдер җитдилек белән, кемдер нарасыйларча куанып утыра. Болары инде - җиңүче малайларның аталары.

Балаларның йөзләренә карыйсың да, шатланып бетә алмыйсың! Алар әле сәясәт белән пычранмаган саф күңелле оҗмах кошчыклары! Бәхетлеләр! Аларның хисләре ап-ак нурга бөркенгән. Хыяллары язгы рәшәдәй дүрт яклап сирпелә дә сирпелә. Ярсыз бәхет диңгезендә йөзәләр.

Ә бит бу әкияти диңгезне аларга Минәхмәт абыйлары Хәлиуллов бүләк итте.

Ярышны оештыручы - Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарият җитәкчесе, Самар шәһәр Думасы депутаты Мидхәт углы Минәхмәт Хәлиуллов. Аның белән түбәндәге сөйләшү булды.

- **Нинди хисләр кичерәсез шундый матур бәйрәмнән?**

- Менә өченче ел инде “Яктылык” мәктәбендә укучылыр арасында көрәш бәйрәме оештырабыз. Бу бәйгегә алар ел буена әзерләнәләр. Өлкә мохтарияте үз акчасына ике тренер тота. Алар - Русиянең спорт осталары Рәшид Үтәшев һәм Руслан Йосыпов. Тренерларыбыз югары тәртипкә ия татар ирләре. Рәшид белән Руслан балаларны яраталар. Ә балалар абыйларын тагын да күбрәк яраталар. “Яктылык”та чын егетләр үстерүгә зур көч куябыз. Татарлар көчле булырга тиеш. Ә көчле ир һәрвакыт гаиләсен бәхетле итә.

- **Самарда 200дән артык мәктәп. Тик “Яктылык”та гына көрәшәләр. Депутат буларак, бәлки, бу мәсьәләне Думада күтәрергәдер?**

- Самарда спорт ярышлары күпләп оештырыла. Дөрес, алар буй җиткән егетләр арасында. Икенче елны үзебезнең көрәшне зуррак залда үткәрү турында уйланам. Аннары, без бит “Яктылык” укучылары белән генә чикләнмибез. Килсеннәр, көрәшсеннәр, көчләрен сынасыннар. Җиңүчеләр исемлегендә Яңа Куйбышев егетләре бар. Самарның «Спартак», «Виктория» клубларыннан һәм Яңа Мансур авылыннан килделәр. Быел грипп көчле булганлыктан, Гали, Камышлы, Ярмәктән килә алмадылар.



Сценарийга соңгы төзәтмәләр

- **Чыгымнарны тулысынча үз өстегезгә алдыгызмы?**

- Чынбарлыкта күтәрә алам. Ләкин дә максатым башка. Татарлар милләт балалары турында уйлап яшәргә өйрәнергә тиешләр. Шул ук эшбатырларның кызларына кияү егетләре үстерәбез бит. Шул фикерне әйткәч, елмая-елмая ярдәм күрсәтәләр.

**Шамил БАҺАУТДИН.**

# Лондонда Муса Җәлилне искә алу кичәсе узды



Бүгенге көндә Самар татар яшьләре алдында бик күп мөмкинлекләр ачылды. Шуларның берсе - чит илдә белем алу. Самар шәһәрендә 11 гимназияне «бишле»ләргә генә тәмамлаган, Самар дәүләт университетын Кызыл диплом белән бетергән милләттәшебез Мәликә туташ Горланова бүгенге көндә Лондонда белем ала. Читләргә киткәч, татарлык хисе көчәя икән, Мәликә милләттәшләре янына сыена. Үзенең татарлыгын ерак утрауда урнашкан Бөекбританиянең башкаласы Лондонда да күрсәтергә җай тапкан. UK Tatar Association Лондонда Муса Җәлилне искә алу кичәсен уздыруда катнашкан. Шуның турыда безгә Мәликә туташ хәбәр итте һәм фотолар да җибәрде.

«Милли ризыклы өстәл тирәсендә эчтәлекле, матур аралашу милләттәшләребезнең белем офыгын киңәйтте, сагыну хисләребезне бастырды, күңелләребезне күтәрде», дип язган Мәликә туташ.

Афәрин, Лондонда яшәүче татарларыбыз!

**Наилә САБИРҖАНОВА.**

# Самарда беренче айнык дискотеканы татарлар уздырды

Самарның иң затлы күңел ачу залларының берсе булган МТЛ «АРЕНА» бинасында бик еш ял кичәләре уздыралар. Һәм, әйтергә кирәк, яшьләр җыелган җирдә хәмер-шәраб шикелле эчемлекләр изнигам сатыла. Шәхси хуҗалык буларак, алар андый кичәләрдән керем ясый. Эчемлек саттырмау буенча ял итү үзәге түрәләре белән бик озак сөйләшүләр алып барылды. Биредә айнык дискотека узачагы турында реклам кампаниясе оештырылды.

Татар яшьләренең ял кичәсен Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте оештырды (рәисе - Минәхмәт Хәлиуллов). Төрле бәйгеләр уздырганлыктан, бик күп бүләкләр әзерләнде. Аларга акчаны Минәхмәт Хәлиуллов һәм Али Сөләйманов бирделәр. Мәдәни программа күпкырлы гына булмады, ул әле татар телендә алып барылды. Шулай да һәр төр уенның иң зурысы була. Бу кичәдә зур сәхнәгә күтәрелеп караокега татар җырын башкарырга кирәк иде. Көтелмәгән хәл. Теләүчеләр сансыз күп булды. Күңел ачу иртәнге алтыга кадәр дәвам иткәнлектән, җырларга теләүчеләрнең барчасы да сәхнәгә күтәрелде. Иң оста җырлаучы Гөлнарага Илйас Шәкүров планшет-кампитр бүләк итте.

Тәнәфесләр ясап, өлкән агаларын да тыңладылар.

“Туган тел” җәмгыяте президенты Илйас Шәкүров яшьләрне үзенең проектларында катнашырга чакырды.

“Шикләнеп кенә тотынган идек, бик әйбәт килеп чыкты”, диде өлкә мохтариятенең яшьләр төркеме җитәкчесе Ригил Курмаев.

Ригил Курмаев әле “Яктылык” мәктәбендә укыганда ук оештыру сәләтенә ия икәнен күрсәтте. Югары белем алып, полиция хезмәткәре булып эшли башлагач, ул тагын да камилләште.

**Ринат САФИН.**

***Уважаемые читатели!***

***В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.***

***Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.***

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.

**Ответственные за выпуск газеты:**
по организационно-финансовым вопросам - **Джавдят ШАРАПОВ,**
по духовно-просветительской части - **Наил СУЛЕЙМАНОВ.**

**Редактор** -
Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
Тел.: 8-937=65-67-616
**932-58-67 (раб.)**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 26.
**Адрес редакции и издателя:**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 29.
E-mail: islam-nur@bk.ru

**Ответственный секретарь -**
Шамил БАГАУТДИН.
**Корреспондент** -
Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Верстка и дизайн** -
Рамил НУРЕТДИНОВ.
**Набор** - Гузел САЛАХОВА.
**Корректор** - Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**
***по установленному графику - 28 февраля 15:00***
***фактически - 28 февраля 15:00***

6+

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**
**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ 324 Тираж 5000.**
***Цена свободная.***
Рег. свидетельство ПИ № ТУ63-00111
Индекс газеты - 52381